Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШТУГАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Иштуган т.ю.т.б., Үзәк урамы, 11 йорт
тел. 8 (84362) 4-20-37

Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан,
П.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, д. 11
тел. 8 (84362) 4-20-37

isht.sab@tatar.ru

2019 нчы елның 06 нчы мае № 22

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты
баш хисапчысыларының һәм хисапчыларының
(муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына
кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын
оештыру һәм түләү шартлары турында

Муниципаль учреждение хезмәткәрләренең хезмәт хакы системасын камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен һәм алар тарафыннан шул ук квалификацияне үтәгәнгә 2019 елның 31 мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким булмаска тиеш.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты 2012 нче елның 19 нчы декабрендә кабул ителгән 20 нче номерлы «Татарстан Республикасы бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Иштуган авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Нигезләмәсен раслау турында» карарын;

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты 2018 нче елның 17 нче апрелендә кабул ителгән 11 нче номерлы «Татарстан Республикасы бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Иштуган авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 нчы елның 06 маенда кабул ителгән
22 нче номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысыларының һәм хисапчыларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Нигезләмә**

1. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты баш хисапчысылары һәм хисапчыларының (алга таба – хисапчылар) (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы әлеге Нигезләмә хисапчылар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфа керемнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Хисапчыларның хезмәт хакын вазыйфа кереме, эшләгән еллар өчен вазыйфа керемен айлык өстәмә, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр тәшкил итә.

3. Хисапчыларның вазыйфа керемнәре түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Башкарма комитетының халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 15 700 сум | 17 000 сум |
| Хисапчы | - | 14 500 сум |

4. Авыл җирлеге башкарма комитеты штат расписаниесенә хисапчы вазыйфасын кертү шарты булып, муниципаль берәмлек халкы саны 3,5 меңнән артык кеше тора.

5. Хисапчыларга билгеләнә:

1) эшләнгән еллар өчен вазыйфа керемен айлык өстәмә түбәндәге күләмнәрдә:

| Эш стаж | Айлык өстәмә, процентта |
|---|---|
| 1 - 5 ел | 5 |
| 5 - 10 ел | 7 |
| 10 - 15 ел | 10 |
| 15 елдан югары | 15 |

2) эш интенсивлыгы өчен вазыйфа керемен вазыйфа кеременең 10 проценты күләмендә айлык өстәмә;

3) һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле ялларга бирелә торган түләү вазыйфа кеременең 120 проценты күләмендә;

Әгәр хисапчыларга һәр ел саен бер тапкыр алына торган түләүле бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрь аенда пропорциональ рәвештә түләнелә, эштән азат ителгән очракта – соңгы эш көнендә.

Беренче елда еллык түләүле отпуск биргәндә хисапчыларга бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елында башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт дәвере эшкә кергән көннән алып шул елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

4) хезмәт хакы өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш нәтиҗәләре буенча премия (премия түләү шартлары, вакытлылыгы, күләме хезмәт хакы өчен түләүнең гамәлдәге шартларыннан чыгып билгеләнә).

6. Бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t);$$

әлеге формулада:

*FOT* - хисапчыларның еллык хезмәт хакы фонды;

*Od* - хисапчыга хезмәт хакы түләү өчен акча суммасы;

*O,3 * Od* - тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфа керемена айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле ял, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;

Р – бухгалтерларның еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган);

*n* - хисапчыларның штат саны;

*k* - 12 ай;

*t* - хезмәт хакын түләү өчен хисаплау.